| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 19.12.2025 | г.Казань | № 671-38/тко-2025 |

Татарстан Республикасы территориясендә Көнчыгыш эшчәнлек зонасында «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә 2026 елга чик дәрәҗәдә бердәм тарифлар билгеләү һәм житештерү программасын раслау турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция һәм житештерү программаларын эшләү, раслау һәм төгәлләштерү тәртибен, шул исәптән эшкәртү, йогышсызландыру, күмү объектларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлы һәм факттагы күрсәткечләрен билгеләү, шулай ук инвестиция һәм житештерү программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 маендагы 424 номерлы, «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карарлары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 19.12.2025 ел, №35-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнчыгыш зонасы буенча төбәк операторы хезмәт күрсәтүләренә әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә календарь буенча бүлеп, чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән иң чик бердәм тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнчыгыш зонасы буенча төбәк операторының җитештерү программасын расларга.

4. «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнчыгыш зонасы буенча төбәк операторына ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 23 гыйнварындагы 109 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2025 № 671-38/тко-2025
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә Көнчыгыш эшчәнлек зонасында «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә 2026 елга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗәдә бердәм тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәте күрсәтүгә чик бердәм тарифлар, сум/куб.метр | |
|---|---|---|---|
| | | 2026 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 октябрьдән |
| 1 | «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 625,19 | 687,08 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 149 статьясының 2 пунктының 36 пунктчасы кулланылмый.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2025 № 671-38/тко-2025
карарына 2 нче кушымта

| Оешманың җитештерү программасы | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты** | | | | | |
| **Җайга салынулы оешма** | «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | |
| Урнашу урыны | 420012, Татарстан Республикасы, Казан ш., Бутлеров ур., 21 й. | | | | |
| **Җайга салучы вәкаләтле орган** | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | | |
| Урнашу урыны | 420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Карл Маркс урамы, 66; | | | | |
| **Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры** | башлана | 01.01.2026 | тәмамлана | 31.12.2026 | |

| **2 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру исемлеге** | | | |
|---|---|---|---|
| **№** | **Атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары** |
| | | | **2026 ел** |
| 1 | Объектларны агымдагы эксплуатацияләү | мең сум | 3 388 491,94 |
| 2 | Агымдагы ремонт | мең сум | 0,00 |
| 3 | Капиталь ремонт | мең сум | 0,00 |

| **3 нче бүлек. Каты коммуналь калдыкларның планлаштырыла торган күләме** | | | |
|---|---|---|---|
| **№** | **Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
| | | | **2026 ел** |
| 1 | Каты коммуналь калдыклар күләме | мең куб.м. | 6 452,63 |

| **4 нче бүлек. Финанс ихтыяҗлары күләме** | | | |
|---|---|---|---|
| **№** | **Күрсәткечнең атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
| | | | **2026 ел** |
| 1 | Региональ операторның үз чыгымнары | мең сум | 2 267 651,05 |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны транспортлау чыгымнары | мең сум | 1 933 897,09 |
| 1.2 | Сату чыгымнары (шикле бурычлар) | мең сум | 29 740,98 |
| 1.3 | Шартнамәләр төзү һәм аларга хезмәт күрсәтү чыгымнары | мең сум | 261 754,02 |
| 1.4 | Контейнерлар һәм бункерлар сатып алу һәм тоту чыгымнары | мең сум | 33 403,31 |
| 1.5 | Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүгә банк гарантиясе бирүгә бәйле чыгымнар | мең сум | 8 855,65 |

<table>
<tr><td>2</td><td>Каты коммуналь калдыкларны эшкәртү һәм (яисә) күмү чыгымнары</td><td>мең сум</td><td>1 119 159,17</td></tr>
<tr><td>3</td><td>Алынмаган керемнәр</td><td>мең сум</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>4</td><td>Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар</td><td>мең сум</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>5</td><td>Җайга салуның узган чорларының икътисадый нигезләнмәгән керемнәре</td><td>мең сум</td><td>112 800,64</td></tr>
<tr><td>6</td><td>Норматив табыш</td><td>мең сум</td><td>99 724,50</td></tr>
<tr><td>7</td><td>Эшкуарларның исәпләмә табышы</td><td>мең сум</td><td>14 757,87</td></tr>
<tr><td>8</td><td>Кирәкле тулай табыш, өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча</td><td>мең сум</td><td>3 388 491,94</td></tr>
<tr><td colspan="4">5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы</td></tr>
<tr><td>№</td><td>Чараның атамасы</td><td colspan="2">План чоры</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="3">Җитештерү программасын гамәлгә ашыру кысаларындагы чаралар каралмаган.</td></tr>
<tr><td colspan="4">6 нчы бүлек. Объектларның нәтиҗәлелек күрсәткечләренең план һәм факт күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2">Күрсәткечнең атамасы</td><td rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td>Күрсәткеч зурлыгы</td></tr>
<tr><td>2026 ел</td></tr>
<tr><td colspan="4">Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә файдаланыла торган объектларның нәтиҗәлелек күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар өчен билгеләнде</td></tr>
<tr><td colspan="4">7 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап</td></tr>
<tr><td colspan="4">Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2024 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында бирелгән.</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге